# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№1** **02 декабрь 2021 ел**

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Әлкәй авыл җирлеге составына керүче
Әлкәй авылында гражданнар
жыены нәтиҗәләре турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Уставы нигезендә 2021 елның 01 декабрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез, 2022 елда 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге гражданнарының 2021 елда җыелган һәм Әлкәй авылында паркны коймалауга материал сатып алганнан соң экономияләнгән 60350,00(алтмыш мең өч йөз илле) сум күләмендә үзара салым акчаларын 2022 елда паркны койма белән әйләндереп алуга ризамы?

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 359 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 185.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 185, «КАРШЫ» » позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Әлкәй торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.
2. Түбәнәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

«Сез, 2022 елда 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге гражданнарының 2021 елда җыелган һәм Әлкәй авылында паркны коймалауга материал сатып алганнан соң экономияләнгән 60350,00(алтмыш мең өч йөз илле) сум күләмендә үзара салым акчаларын 2022 елда паркны койма белән әйләндереп алуга ризамы.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Әлкәй авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Әлкәй авыл җирлеге башлыгы С.З.Зиннурова

АЛЬКЕЕВСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1602002494 КПП 164301001